**Хәерле көн , хөрмәтле коллегалар!**

Хәзерге чорда Россия федерациясе тарафыннан милләтне сәламәтләндерүгә җентекле игътибар бирелә. “Здоровье” исемле милли проектны үтәү чаралары даими рәвештә алып барыла.

Балалар бакчасында шәфкать тутуашлары эшенең төп максаты – балаларның тормыш иминлеген һәм сәламәтлеген саклау, ныгыту.

Сәламәтлендерү эше 2013 нче елда балалар бакчасының иҗади төркеме тарафыннан төзелгән, Роспотребнадзор аша 21.08.2024 нче елга тикле расланган “Здоровье” программасы буенча алып барыла.

Сәламәтлекне ныгыту эше физик сәламәтләндерү, профилактик дәвалау, рациональ туклану юнәлешендә эшләнелә.

Белгәнегезчә, балалар бакчасында балаларны кондэлек ашату 2017 елнын 1 июленнэн Казан депортамент системасына кучте. Хэзерге көнгә кадәр шул идарә белән эшлибез.

Балалар бакчасында балаларны сәламәтләндерү өчен матди - техник чаралар тудырылган:

-сәламәтләндерү үзеге, аның составына физкультура залы, үлән төннәтмәләре эчү бүлмәсе фитобар эшләп килә;

-медицина узәге, аның составына изолятор, медиклар бүлмәсе кергән;

-балалар бакчасы территориясендә спортплощадка, ачык бассейн җиһазландырылган.

Физик тәрбия бирү эшләре тәрбиячеләр тарафыннан алып барыла.

Физкультура шөгыльләрендә эш физик тәрбия бирү нормаларына туры килә һәм 60-80% (физическая нагрузка и мотороная плотность) тәшкил итә.

Иртәнге гимнастика комплексына, физкультура шөгыльләренә сулау күнегүләре, гәүдә торышын һәм аю табанын профилактикалау биремнәре кертелә.

Чыныктыру чараларыннан 2,9,6 нчы түркемнәрдә: йодлы- тозлы юлда йөрү һәм табан астын массажерлар ярдәмендә чыныктыру 1,5,7,8 4,3 нчы төркемнәрдә - йога элементлары,нокталы массаж, котрастлы һава ваннасы кертелгән.

Балалар бакчасында суык тиюгә һәм гриппка каршы чаралар алып барыла: температура режимын контрольдә тоту, сарымсак-суганлы ароматизаторлар куллану, иртәнге фильтрны эзлекле алып бару, чирләүчеләрнең балалар бакчасына йөрүен чикләү, оксолин мае сөртү, үлән чәйләре эчерү, витаминнар куллану. Гриппка каршы прививка планлы рәвештә- 95 балага ,32 хезмәткәргә ясалды.

Үлчәү графигы балаларны планлы тикшерү вакытында үтәлә. Балаларның буй һәм тән авырлыклары яшь буенча нормага туры килә. Үлчәү графигын куздэ тотып балаларны уз урыннарына утыртыла. Специалистлар тарафыннан балаларны күзәтү планлы рәвештә оештырыла.

Сәламәтлек буенча кимчелекләре булган балалар учётка куела, күзәтү астына алына, сәламәтләндерелә. 2024 нче елда 1 балага туры килгән авырган көннәр саны 3,0 кон тәшкил итә. Ә 2023 нче елда ул күрсәткеч 4,1 кон иде. Димәк, бакчада авыру очраклары кимегән. Чагыштыру өчен шәһәр куләмендә 3,8 кон .
**9,7 нче төркемнәрендә авыру очраклары куп. Ул бер балага 3,6 көн.**

## Авыру очраклары күрсәткечләре

| | | 2022 | 2023 | 2024 |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Балалар саны | 218 | 214 | **127** |
| 2 | Авыру очраклары саны | 940 | 947 | **383** |
| 3 | 1 балага туры килгән авырган көннәр саны | 3,8 | 4,1 | **3,0** |

## Авыру очракларының чагыштырмача күрсәткечләре

| Ел | Город | ДОУ №49 | ДОУ №69 |
|---|---|---|---|
| 2024 | 3,8 | 3,0 | 3,9 |

## Төркемнәр буенча авыру очраклары күрсәткечләре:

| | №1 | №2 | №3 | №4 | №5 | №6 | №7 | №8 | №9 | гомуми |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2024 | 30 | 14 | 34 | 44 | 8 | 32 | 77 | 27 | 115 | 383 |

## Сәламәтлек төркемнәре

| Сәламәтлек төркемнәре | 2022 | 2023 | 2024 |
|---|---|---|---|
| I | 75 | 67 | 69 |
| II | 98 | 78 | 50 |
| III | 5 | 2 | 2 |
| IY | - | - | - |

## Чирләмәүче балалар саны : (индекс здоровья).

| Ел | Балалар саны | % |
|---|---|---|
| 2022 | 167 | 61,9 |
| 2023 | 127 | 55 |
| 2024 | 121 | 69,9 |

## Адаптация күрсәткечләре.

| | Килгән балалар саны | Жиңел очрак | Уртача очрак | Авыр очрак |
|---|---|---|---|---|
| 2022 | 49 | 44/90 | 5/10,2 | - |
| 2023 | 52 | 45/86,5 | 7/13,4 | - |
| 2024 | 24 | 21/87,5 | 3/12,5 | - |

Сәламәтләндерү эше бала бакчага килгән көннән, адаптация чараларыннан башлана.Үткәрелгән чараларның төрләре дә, эчтәлеге дә яңа килгән балаларның ата- аналары өчен бик кирәкле :”Балалар бакчасына ничек тиз ияләнергә”,”Күз яшеннән башка” һ.б.исемле консультацияләр, киңәшләр, әңгәмәләр,тәгъдимнәр,

памяткалар. Балаларның адаптациясе беренче атнада 2 сәгатьтән башланып, чикләнешле режим белән дәвам итте: белем уен аша гына бирелде.

Хезмәт саклау, куркынычсызлык техникасы комиссиясе утырышларында балаларның һәм хезмәткәрләрнең имгәнү очракларын чикләү сораулары, ата-аналар белән профилактик- агарту эшләре алып бару сораулары карала.

Балалар бакчасында имгәнү очраклары теркәлмәде. Системалы рәвештә инструктажлар уткәрелә;3- баскычлы контроль алып барыла: территория,төркемнәр, заллар,бүлмәләр, подвал,складлар карала.

Күрсәткечләрне анализлау аша сәламәтләндерү эзлекле рәвештә алып барыла дип инкар итәргә була. Шуны әйтәсе килә, балаларнын бакча йореше яхшы күрсәткечкә ия булып, рейтинг барышында максималь 6,0 балл яулады..

Чирләү очракларын кимүендә хезмәткәрләрнең зур өлеше бар.Тәрбияче ярдәмчеләре дә бу эшкә зур өлеш кертә. Мин аларга бик зур рэхмэтлемен Без алардан нинди генә ярдәм сорасак та тиз һәм жиренә житкереп башкаралар. Ләкин киңәш ителгән сораулар буенча эшләргә кирәк әле. Бу кинәшләр күбрәк САН пин кагыйдәләрен үтәү буенча.

2017 елнын 1 июленнэн кондэлек балаларны ашату Казан дипортамент системасына кучкэн иде, ашату хаман бу учреңдение белән алып барыла.

**Туклану нормаларының үтәлеше күрсәткечләре**

| **ризык/еллар** | **2022** | **2023** | **2024** |
|---|---|---|---|
| **Ит/мясо** | 99 | 89 | **100%** |
| **Сөт/молоко** | 96 | 95 | **100%** |
| **Җиләк-җимеш/ фрукты свежие** | 90 | 87 | **94%** |
| **Яшелчә/овощи** | 91 | 85 | **92%** |
| **Балык/рыба** | 92 | 89 | **94%** |

Норманың үтәлеше арткан. Җиләк-җимеш, яшелчәнең нормасының үтәлешен контрольдә тотарга кирәк. Бу эштә безнең шеф поваробыз Татьяна Виктор кызының осталыгы, кладовщигыбыз Венера Викторовнаның җитезлеге,поварларыбыз Светлана Фэйзулла кызы, Татьяна Викторовнаның кызының тәмле пешерүләре, Мәймүнә Габдулкалимовна белән Евдокия Петровнаның ярдәмнәре белән күтәрелгән.

**Медик агарту эшләренең күрсәткечләре**

| | Санбюллетень | Әңгәмә | Лекция | Консультация | Сәламәтлек почмагы |
|---|---|---|---|---|---|
| 2023 | 22 | 150(960кеше) | 3(102кеше) | **242** | 14 |
| 2024 | 28 | 140/840 кеше | 3/98 кеше | **230** | 14 |

Производства контроле (проверка территориального органа службы по надзору и контролю в сфере защиты прав потребителей и благополучия человека по РТ-Роспотребнадзор) 2024 нче елда хәр квартал үткәрелде (4 тапкыр). Лаборатор тикшерудә барлык анализлар яхшы булып протоколлар алынды. Роспотребнадзор комиссиясе рәисе коллективның эш бурычларын төгәл үтәүен ассызыклап үтте, шәфкать туташларының системалы эш алып баруын билгеләде.Бакчаны уку елына әзерләүдә югары балл куелды.

**Мин, шәфкать туташы буларак, коллективка рәхмәтемне белдерәм. Куелган бурычларны бергә үтәрбез дип ышанып калам.**